Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге Советының илле сигезенче утырышы

Пимәр авыл җирлеге Советы

**КАРАРЫ**

29 май, 2020 ел № 146

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге Советының 2015 елның 12 маендагы 12 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» гы карарына үзгәрешләр һәм төгәлләштерүләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге советы карар чыгарды:**

1. «Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында» 2015 елның 12 маендагы 12 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм төгәлләштерүләрне кертергә:

1.1. Карар һәм кушымта исемендә, шулай ук 1 пункт текстында «өченче чакырылыш» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге Советы карарына кушымта 2015 елның 12 маендагы 12 номерлы Пимәр бермандатлы сайлау округларына түбәндәге йортларны кертеп төгәлләштерергә:

- Пимәр № 2 бермандатлы сайлау округына Совет урамы буенча 70 нче йорт;
- Пимәр № 4 бермандатлы сайлау округына Пионер урамы буенча 66А нчы йорты;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ✱ ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ✱ МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПИМЕРСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СОВЕТ ПИМЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1633002916